



# КАЙДА ДА – ҮЗ ӨЕНДӘ...

Виктория Егорова. Бу исем минем өчен яңа. Картиналары да ачыш булды. Үзе белән танышканчы, башта картиналары килеп керде дөньяма. Виктория үзе Казанда түгел иде, Индонезиядә – арт-фестивальдә, 20 ил арасында Россияне тәкъдим итүче бердәнбер рәссам буларак катнаша. Танышырга мөмкинлек килеп чыкмый да чыкмый. Шунда уйлап куйдым: бәлки, үзен белергә кирәк тә түгелдер? Сурәтләре аша җибәргән хәбәре – шул да бик җиткән. Җан биографиясе бит барыбер – иҗатта.

Әмма сурәтләренә ныграк күмелгән саен, сораулар күбрәк туа башлады. Сөйләшү зарурлыгы – арта...

«Күпчелек эшләрем эмоция-тәэсирләргә нигезләнгән. Башка илләргә сәяхәт иткәндә җыеп кайткан тәэсирләрме ул, шәһәр читенә чыгып кергән кечкенә генә сәфәрнекеме – кайда нәрсә көтеп торганын белмисең бит. Фәрештәләр яисә Галәмдәге бүтән көчләр белән бәйләнешне тоюдан туган сурәтләр дә бар, болары инде интуиция өлкәсенә карый, монда сүзләр артык...»

«Фәрештә пышылдавы» мине бер күрүдә үк җәлеп итте. Рәссамның дөньясында ялгызлык бөтенләй диярлек юк, булганда да ул – фәрештәле, гармонияле. Икенче бер картинасы – «Тынлык» – икәүнең бөтенлек тойгысында изрәве, гавамнан аерылып, үз аңлашу утрауларына йомылуы. Бу ике сурәт башка картиналарыннан аерылып тора. Мин аларны үзенә күрә бер диптих буларак кабул иттем. Бар да очып китәрдәй җиңел һәм йомшак-садә монда – кызның ап-ак челтәр күлмәге, чәчендәге такыясы да, туташны коендырган алтынсу нур, чәчләренә орыныр-орынмас тибрәнүче таҗын очырган тузганаклар да...

«Төркия циклы» кешеләр бердәмлеген, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең табигый җылылыгын бәркеп тора. «Бу серия Төркиядәге халыкара күргәзмәдә булып кайткаsuccessfully каннан соң язылды. Анда мин таулардагы борынгы авылларда йөрдем. Гаҗәеп колоритлы урыннар. Ә өлкән кешеләрнең гадәти тормыш-көнкүреше – үзе бер фәлсәфә».

Чыннан да, шәркый рухны, бер-берсе белән тыгыз үрелгән эшлекле, туганнарча, дусларча мөнәсәбәтләрне нечкә итеп «тотып» ала алган Виктория. Базарда сату итүче агайлармы ул, кафеда утыручы яшьләрме, алма җыючы яки палас сатучы хатыннармы – борынгы традицияләр, милли-җирле рух бөркелеп тора һәммәсеннән.

«Институтны тәмамлаган гына елларда натюрмортлар, пейзажлар яза идем, ул үзенә күрә бер шундый чор булды, ахрысы. Хәзер инде миңа күп фигуралы киндерләр ошый, мин алар аша нәрсә җиткерергә теләгәнемне тоемлый башладым. 2014–2015 еллардагы эшләрем сериясендә мин үзебезнең халыкның көнкүрешен, җирле колоритны чагылдырырга тырыштым».

Ретроспектива ясап, Викториянең натюрмортлар һәм пейзажлар чорына «сикерәм». Һәм... ялгызаграк дөньяга юлыгам. Анда кешеләр юк диярлек, булса да, күләгәләр генә. Мәңге еламсырак Питерның яңгырларына, тымызык томаннарына сеңеп беткән тап-буяулар алар...

«Үз-үземә китеп, бикләнеп тору бик мөһим минем өчен», – ди Виктория. Монысы аңлашыла. Барыбыз да шундый. Миңа аның башка фразасы ошады. Бик символик тоелды: «Мин үз шәһәремне, туган илемне, Россияне бик яратам, әмма иҗат кешесе үзен билгеле бер җирлек, милләт, ил кысаларына гына кертеп «бикләргә» тиеш дип санамыйм. Кайда барсам да, үземне өйдәгедәй хис итәм...»

Бәлки, шуңа туганлык тоямдыр аның образларына карап – төрек агайларымы ул, утраклыкка күчкән чегәннәрме... кызның колагына нидер пышылдаучы фәрештәме. Ул да бит – Туган Йорт символы...

*Луиза ЯНСУАР*